Рушания Гыйләҗевадан - затлы бүләкләр : [Казанда «Ногай» кунакханәсенең Тукай залында язучы Рушания Гыйләҗеваның «Хәрефләр өйрәнәбез» һәм «Мәрҗән төймә» исемле китапларын тәкъдим итү кичәсе узды]. – Текст: турыдан-туры // Шәһри Чаллы. – 2026. – № 6 (30 гыйнвар). – Б. 12.



# Рушания Гыйләҗевадан – затлы бүләкләр



Фотода: Рушания Гыйләҗева Аяз Гыйләҗевнең улы Искәндәр һәм хатыны Нәкыя апа белән.




**Казанда «Ногай» кунакханәсенең Тукай залында шәһәрдәшебез, язучы Рушания Гыйләҗеваның «Хәрефләр өйрәнәбез» һәм «Мәрҗән төймә» исемле китапларын тәкъдим итү кичәсе узды.**

Чарада иң элек 2021 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Әлифба» китабы турында сүз барды. Анда татар алфавитындагы 39 хәрефкә багышланган 39 шигырь урын алган. Доцент, галимә Миләүшә Хабетдинова билгеләп үткәнчә, Рушания Гыйләҗеваның әлеге иҗат җимешләре Корней Чуковский традицияләрен хәтерләтеп, балалар өчен мавыктыргыч һәм җанлы итеп язылган. Ул шулай ук 2025 елда Казанда дөнья күргән «Мәрҗән төймә» җыентыгына да фәнни анализ ясаячагын әйтте.

Язучы Аяз Гыйләҗевнең тормыш иптәше Нәкыя ханым үз чыгышында Гыйләҗевлар нәселен иҗади нәсел дип атап, Рушания ханымның шул дәвамның лаеклы вәкил булуын ассызыклады. Тарих фәннәре докторы Искәндәр Гыйләҗев исә балачак хатирәләре белән уртаклашып, «аның кулында һәрвакыт китап булыр иде», — дип искә алды.

Кичәдә милләт темасына язылган җырлар белән ТР атказанган артисты Флүрә Талипова чыгыш ясады. Рушания Гыйләҗева үзе дә тамашачыларга Зөлфия Җиһан көенә иҗат ителгән «Татлы сөю»не һәм татар халык җыры «Карлыган»ны башкарды.

Танылган балалар шагыйре Йолдыз Шәрәпова Рушания ханымның балалар өчен язган әсәрләренә югары бәя бирде. Шагыйрә Әлфия Гәбдрәшитова «Татар теле» шигырен яттан сөйләде, ә Суфия Мостафина «Мәрҗән төймә» китабындагы хикәяләргә анализ тәкъдим итте.

Чыгыш ясаучылар арасында шагыйрә, язучы, журналист Фирдәүсә Бикмәтова, башкаланың 96 нчы гимназиясе укытучысы Альмира Закирова да бар иде. Аларның фикерләре дә кичәнең эчтәлеген баетты.

Иҗат кичәсе Рушания Гыйләҗеваның туганнарын, дусларын да бергә җыйды. Көтелгән кунак, җырчы — Сәнифә Рангулова да чарага аерым җылылык өстәде.

Чараны ТР китап нәшриятының баш мөхәррир урынбасары Венера Шәмсетдинова әзерләде. Ул: «Яңа китаплар татар телен саклауда һичшиксез үз өлешен кертер, алар затлы бүләккә тиң дип ассызыклап үтте.